ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 16 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 2 өлешендә «дәүләт» сүзен «Татарстан Республикасының дәүләт мәгариф оешмаларына» сүзләренә алмаштырырга;

2) 25 статьяда:

а) исемендә «Педагог хезмәткәрләргә социаль ярдәм» сүзләрен «Мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә социаль ярдәм» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Авыл торак пунктларында, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм эшләүче педагог хезмәткәрләр, мәгариф оешмалары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары торак урын, җылылык һәм яктылык өчен түләү чыгымнарына компенсация бирелүгә хокуклы. Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының, муниципаль мәгариф оешмаларының педагог хезмәткәрләренә, әлеге мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, әлеге мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына шушы социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплау күләме, шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән тәэмин ителә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясының 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясының 1 пункты 2020 елның 1 августыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 18 июль
№ 38-ТРЗ